ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕСУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

**Карар** **Постановление**

**№ 19** **«25 » март 2025 ел.**

**Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 N 131-ФЗ, "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 14.07.2022 N 269-ФЗ Федераль законнары, Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге Уставы нигезедә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесен хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында Карар кабул итәргә вәкаләтле зат дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче: Р.Ш.Гафиятуллин

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25.03.2025 ел , № 19 карарына
1 нче № кушымта

**Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә хуҗаларыннан башка хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеге**

Хайваннарны приютта стерильләштерү, тамгалау, исәпкә алу, карантинлаштыру, дәвалау, вакцинацияләү чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яисә кешегә карата мотивацияләнмәгән агрессивлык күрсәтмәгән очракта, әгәр мондый хайваннарны приютларда, территориядә һәм 500 метрдан якынрак ераклыкта тоту мөмкинлеге булмаса, хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына (тотылган ау урынына) кире кайтару тыелу урыннары:

- авыл җирлеге хакимияте,

- социаль өлкә учреждениеләре;

- сәламәтлек саклау объектлары;

- мәгариф учреждениеләре (мәктәпләр, балалар бакчалары);

- мәдәният объектлары;

- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары;

- җәмәгать территорияләре (бакчалар, парклар, скверлар, торак пунктларның урамнары, мәйданнары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары);

- площадок для проведения массовых мероприятий;

- стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары, сәүдә нокталары территорияләре;

- зиратлар һәм мемориаль зоналар.